**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2026 елның 8 маендагы 1593 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 6 мартындагы 590 номерлы «Казан шәһәре Мәскәү районында ачык сервитут билгеләү турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип тану хакында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 48 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, «Стройпроект» җитештерү-төзелеш компаниясе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте гаризасы нигезендә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 6 мартындагы 590 номерлы «Казан шәһәре Мәскәү районында ачык сервитут билгеләү турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**